**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГЫЙ БАЙЛЫКЛАР МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

21.07.2017 825-П

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәре вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгындагы Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре аларда һәркем ала алырлык информация, шулай ук аларны идентификацияләү мөмкинлеге бирә торган мәгълүматлар урнаштырган «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре сайтлары һәм (яки) сайт битләре турында мәгълүматларны кабул итү, эшкәртү һәм тикшерү Тәртибен раслау турында

2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе дәүләт гражданлык хезмәте турында» Федераль законның 20.2 маддәсе, 2003 елның 16 январендагы 3-ЗРТ номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәте турында» Татарстан Республикасы Законының 17.2 маддәсе нигезендә боерык бирәм:

1. Кушымтада бирелә торган Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәре вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгындагы Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре аларда һәркем ала алырлык информация, шулай ук аларны идентификацияләү мөмкинлеге бирә торган мәгълүматлар урнаштырган «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре сайтлары һәм (яки) сайт битләре турында мәгълүматларны кабул итү, эшкәртү һәм тикшерү Тәртибен расларга.

2. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Министр Ф.С. Габделганиев

Татарстан
Республикасы
экология һәм табигый
байлыклар
министрының
21.07.2017 № 825-п
боерыгы белән
расланды

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәре вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгындагы Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре аларда һәркем ала алырлык информация, шулай ук аларны идентификацияләү мөмкинлеге бирә торган мәгълүматлар урнаштырган «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре сайтлары һәм (яки) сайт битләре турында мәгълүматларны кабул итү, эшкәртү һәм тикшерү тәртибе

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәре вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар һәм Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгындагы Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре аларда һәркем ала алырлык информация, шулай ук аларны идентификацияләү мөмкинлеге бирә торган мәгълүматлар урнаштырган «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре сайтлары һәм (яки) сайт битләре турында мәгълүматларны кабул итү, эшкәртү һәм тикшерү тәртибе (алга таба – Тәртип) билгели:

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәре вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы гражданнар (алга таба – гражданин) һәм Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгындагы Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре (алга таба – гражданлык хезмәткәре, Министрлык) тарафыннан алар һәркем ала алырлык информация, шулай ук аларны идентификацияләү мөмкинлеге бирә торган мәгълүматлар урнаштырган «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре сайтлары һәм (яки) сайт битләре турында мәгълүматларны тапшыру кагыйдәләрен (алга таба – Сайтлар турында мәгълүматлар, “Интернет” челтәре);

Сайтлар турында мәгълүматларны кабул итү һәм эшкәртү тәртибен;

Сайтлар турында мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү тәртибен.

2. Һәркем ала алырлык информация астында 2006 елның 27 июлендәге № 149-ФЗ "Информация, информацион технологияләр һәм информацияне саклау турында" Федераль законның 7 маддәсенең 1 өлеше нигезендә гомумбилгеле мәгълүматлар һәм аны алу мөмкинлеге чикләнмәгән бүтән төр информация аңланыла. Шул ук вакытта информация алуда чикләүнең булмавы чикләнмәгән даирә затларның урнаштырылган информацияне гражданлык хезмәткәре яки гражданин ризалыгыннан башка каршылыксыз алу һәм үз карамагы буенча файдалану мөмкинлеген күздә тота.

3. Гражданлык хезмәткәре яки гражданин шәхесен идентификацияләргә мөмкинлек бирә торган мәгълүматлар сыйфатында түбәндәге мәгълүматлар җыелмасы яки аларның берсе торырга мөмкин: фамилия һәм исем, фотография, хезмәт урыны.

## II. Сайтлар турында мәгълүматларны кабул итү һәм эшкәртү тәртибе

4. Сайтлар турында мәгълүматлар тапшыралар:

гражданин - Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәтенә кергәндә (алга таба – гражданлык хезмәте), гражданлык хезмәтенә кергән елдан алдагы өч календарь ел өчен;

гражданлык хезмәткәре – ел саен хисап елыннан соң килә торган елның 1 апреленнән соңга калмыйча, үткән календарь ел өчен.

5. Сайтлар турында мәгълүматлар гражданнар һәм гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән форма буенча тапшырыла (алга таба – Форма).

6. Һәркем алырлык информация, әгәр ул гражданлык хезмәткәренең вазыйфаи йөкләмәләрен үтәү кысасында куелган булса, Формада чыгылдырылырга тиеш түгел.

7. Тутырылган Форма гражданлык хезмәткәре яки гражданин тарафыннан дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегенең Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министры боерыгы белән Сайтлар турында мәгълүматларны эшкәртүне гамәлгә ашыру өчен җаваплы итеп билгеләнгән хезмәткәренә (алга таба – җаваплы зат) тапшырыла.

8. Җаваплы зат Форманы тутыруның тулылыгын, анда күрсәтелгән мәгълүматларның дөреслеген «Интернет» челтәрен файдаланып тикшерә, шәхси имзасын куя, Форманы кабул иткән көнне мәгълүматларны әлеге Тәртипкә Кушымтага туры килгән форма буенча журналга кертә.

9. Тутырылмый калган урыннары булган Форма кабул ителергә тиеш түгел.

10. Гражданин тарафыннан тапшырылган Формада дөрес булмаган мәгълүматлар табылган очракта, дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлеге аңа гражданлык хезмәте вазыйфасына билгеләүдән баш тарту турында тиз арада белдерә.

11. Сайтлар турында мәгълүматлар җаваплы зат тарафыннан гражданлык хезмәткәрләренең “Татарстан Республикасында дәүләт гражданлык хезмәтенең һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәтнең кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы” Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасындагы шәхси карточкаларына кертелә.

12. Гражданлык хезмәткәрләре һәм гражданнар тарафыннан тапшырылган формалар дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегендә биш ел дәвамында саклана, аннан соң Министрлыкта персональ мәгълүматларны эшкәртү кагыйдәләре белән билгеләнгән тәртиптә юк ителергә тиеш.

## III. Сайтлар турында мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү тәртибе

13. Гражданлык хезмәткәрләре тарафыннан тапшырылган Сайтлар турында мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министры (министр вазыйфаларын башкаручы зат) (алга таба – Министр) боерыгы буенча башкарыла.

14. Тикшерү өчен нигез булып, түбәндәгеләр тарафыннан язмача формада бирелгән җитәрлек күләмдәге информация тора:

хокук саклау органнары, бүтән төр дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм аларның вазыйфаи затлары;

сәяси партияләрнең һәм законга туры китереп теркәлгән, сәяси партия булмаган бүтән гомумроссия, регионара һәм региональ иҗтимагый берләшмәләрнең даими гамәлдәге җитәкче органнары;

Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы;

Гомумроссия һәм республика массакүләм мәгълүмат чаралары.

15. Җаваплы зат гражданлык хезмәткәренә аңа карата тикшерү башлануы турында тикшерү үткәрү турында боерык чыккан көннән алып ике эш көне дәвамында язмача формада белдерә.

16. Гражданлык хезмәткәре тапшырган Сайтлар турында мәгълүматларның дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү җаваплы зат тарафыннан «Интернет» челтәрендә ул урнаштырган һәркем алырлык информацияне эзләү һәм күрсәтелгән информациянең электрон күчермәләрен (скриншотларын) ясау юлы белән гамәлгә ашырыла.

17. Гражданлык хезмәткәре тикшерү барышында һәм тикшерү нәтиҗәләре буенча язма формада аңлатмалар бирергә, өстәмә материаллар тапшырырга хокуклы.

18. Әлеге Тәртипнең 17 пунктында күрсәтелгән аңлатмалар тикшерү материалларына беркетелә.

19. Тикшерү материаллары һәм тикшерү барышында җыелган информация тикшерү үткәрү турында боерык чыгарган көннән алып 10 эш көненнән артмаган срокта Министрга тапшырыла.

20. Тикшерү нәтиҗәләре буенча 5-көнлек срок эчендә Министр карар

кабул итә:

гражданлык хезмәткәренә карата юридик җаваплылык чаралары куллану өчен нигезләр булмавы турында;

гражданлык хезмәткәренә карата юридик җаваплылык чаралары куллану турында;

тикшерү материалларын, хокук бозу, җинаять, экстремистик эшчәнлеккә катнашканлык билгеләре булганда, дәүләт органнарына аларның компетенциясе нигезендә җибәрү турында.

21. Җаваплы зат Министр кабул иткән карар турында аңа карата тикшерү үткәрелгән гражданлык хезмәткәренә ике эш көне дәвамында язмача хәбәр итә.

22. Сайтлар турында мәгълүматлар Министрның язмача килешүе белән, бер үк вакытта аңа карата тикшерү үткәрелгән гражданлык хезмәткәренә бу турыда хәбәр итеп, Россия Федерациясенең персональ мәгълүматлар һәм дәүләт сере турындагы законнарын саклап, тикшерү өчен нигез булып торган информацияне биргән хокук саклау органнарына, сәяси партияләрнең һәм законга туры китереп теркәлгән, сәяси партия булмаган бүтән гомумроссия, регионара һәм региональ иҗтимагый берләшмәләрнең даими гамәлдәге җитәкче органнарына, Татарстан Республикасының Иҗтимагый палатасына, гомумроссия һәм республика массакүләм мәгълүмат чараларына тапшырылырга мөмкин.

23. Тикшерү материаллары ул тәмамланган көннән алып өч ел дәвамында Министрлыкның дәүләт хезмәте һәм кадрлар бүлегендә саклана, аннан соң архивка тапшырыла.

## IV. Сайтлар турында мәгълүматлар тапшырмаган өчен җаваплылык

24. Сайтлар турында мәгълүматлар тапшырмаган очракта гражданин гражданлык хезмәтенә кабул ителә алмый, ә гражданлык хезмәткәре гражданлык хезмәтендә тора алмый.
Гражданлык

Татарстан Республикасы
экология һәм табигый
байлыклар министрының
21.07.2017 № 825-п боерыгы
белән расланган Тәртипкә
кушымта

Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәре вазыйфаларын биләүгә дәгъва кылучы граждannar һәм Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгындагы Татарстан Республикасы дәүләт гражданлык хезмәткәрләре аларда һәркем ала алырлык информация, шулай ук аларны идентификацияләү мөмкинлеге бирә торган мәгълүматлар урнаштырган «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре сайтлары һәм (яки) сайт битләре турында тапшырылган мәгълүматларны исәпкә алу журналы

| № т.б. | Форманы тапшыру/ кабул итү датасы | Форманы тапшыручының ФИО | Форманы тапшыручының вазыйфасы (гражданин дәгъва итә торган вазыйфа) | Форманы тапшыручының имзасы (яки форма почта аша килгәндә, № к.т.) | Форманы кабул иткән затның ФИО | Форманы кабул иткән затның имзасы | Тикшерү турында информация (боерык реквизитлары, тикшерү нәтиҗәсе) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |